Автобиография казанского купца Ахметзяна Сайдашева



Известный предприниматель общественный деятель и благотворитель Ахметзян Сайдашев родился в 1840 г. в д. Татарский Кабан Лаишевского уезда Казанской губернии, где еще в начале XIX в. обосновался его отец — имам-хатиб Яхья Сайдашев.

Получив начальное образование в сельском мектебе, в 1852 г. он поступил на учебу в знаменитое Апанаевское медресе г. Казани, которым руководил прославленный богослов и мударрис Мухаметкарим Мухаметрахимов. Впрочем, пребывание сына деревенского муллы в стенах этого учебного заведения было недолгим. Через три года, вследствие материальных затруднений, Ахметзян Сайдашев нанялся на работу к торговцу мехом купцу Габдельвали Козлову. Сайдашев зарекомендовал себя с самой лучшей стороны, и купец дал своему юному подопечному самые лучшие рекомендации, когда на Ахметзяна обратил внимание крупный торговец, купец 1-й гильдии Мухамедгали Габсалямович Усманов. Именно он ввел А. Я. Сайдашева в мир коммерции и помог ему создать основу будущего состояния.


В 1870 г. Ахметзян Сайдашев учредил в Казани торговый дом по продаже чая и кожевенных изделий. С течением времени он утвердился в этой области в качестве монополиста. Это было время головокружительного успеха Сайдашева: современники стали называть Ахметзяна «чайным королем», поэты восторженно отзывались о нем в своих произведениях. К этому времени Сайдашев завершил строительство великолепного особняка в Старотатарской слободе на Большой Мещанской улице (ныне ул. Нариманова, д. 63).

Обладая внушительным капиталом, купец решил направить его на скупку земли, недвижимости, организацию промышленного производства. В 1890 г. он купил у наследников купца Желтухина стекольно-скипидарный завод в Царевококшайском уезде Казанской губернии. 17 июня 1894 г. Сайдашев учредил одно из первых в татарской истории акционерных обществ — товарищество на паях «Торгово-промышленное товарищество Ахметзян Сайдашев с сыновьями и Бакий Субаев в Казани» с уставным капиталом в 500 тысяч рублей. Продукция этой фирмы — чай, сахар, стекло, аптечная посуда, бутылки — сбывалась в Казани, Ростове-на-Дону, Нижнем Новгороде, на Кавказе, а также в некоторых государствах Европы.


Богатство семьи Сайдашевых существенно выросло в 1893 г., когда с отцом



Дом купца А. Сайдашева (ул. Нариманова, д. 63), современный вид. 2007 г. Фото Р. Салихова.



Продукция товарищества «Наследник Желтухина и Ахметзян Сайдашев в Казани». 1890 г. По старым улицам казанским… Казань в фотографиях XIX — начала XX века: Путеводитель-фотоальбом. – Казань, 2005. – С. 113.



Продукция «Торгового дома Б. Субаева, И. Бурнаева и М. Сайдашева». 1890 г. По старым улицам казанским… Казань в фотографиях XIX — начала XX века: Путеводитель-фотоальбом. – Казань, 2005. – С. 113.

объединил свою торговую деятельность старший сын Мухаметзян Сайдашев (1864-1914), являвшийся с 1888 г. вкладчиком «Торгового дома Б. Субаева, И. Бурнаева и М. Сайдашева», специализировавшегося на продаже пушнины.

Ахметзян Сайдашев прославился и как щедрый благотворитель. Он был организатором первой в национальной истории мусульманской богадельни, стоял у истоков Мусульманского благотворительного общества, на протяжении нескольких десятилетий возглавлял мусульманскую группу в городской думе, активно участвовал в работе партии «Иттифак аль-муслимин», являлся ведущим финансистом джадидского образования в Казани и губернии. Он сделал многое для благоустройства татарских слобод Казани: устройство в них электрической и водопроводной сети, системы медицинского обслуживания.

Общественные позиции предпринимателя укреплялись с каждым днем. За глаза горожане называли Сайдашева «татарским губернатором Казани». Власти же, крайне недовольные общественной активностью купца, который организовал общероссийскую петиционную кампанию по отмене закона об образовательном цензе для мусульманского духовенства от 12 июля 1888 г., даже подумывали о высылке его за пределы губернии.

А. Сайдашев вырастил двух сыновей — Мустафу и Мухаметзяна, последний из которых на протяжении многих лет являлся одним из самых активных и энер-

гичных гласных городской думы.

Отец и сын Сайдашевы сыграли огромную роль в национальном возрождении начала XX в. Их взгляды претерпели существенную эволюцию от жестких охранительных позиций до признания насущной необходимости решительных социальных и культурных преобразований в жизни нации. Свои идеи Сайдашевы проводили через открытую ими 31 марта 1906 г. газету «Баянельхак» (Разъяснение истины), представлявшую интересы умеренного крыла национальной буржуазии. Специально для ее издания 16 июня 1907 г. М. А. Сайдашев открыл одноименную типографию, которая за время своего существования выпустила 75 книг общим тиражом 220 тысяч экземпляров.

Публикуемая сегодня на страницах журнала автобиография Ахметзяна Сайдашева является редким и весьма содержательным источником по истории татарского предпринимательства. Она детально характеризует не только особенности становления и развития национального капитала, но и степень влияния торгово-промышленного класса на общественно-политические процессы, происходившие в мусульманском сообществе России во второй половине XIX в. Хронологически документ охватывает период до 1888 г. Можно предположить, что работу над автобиографией купец начал незадолго до своей кончины и поэтому не сумел довести до конца задуманные мемуары. Это незавершенное жизнеописание было опубликовано сразу же после смерти А. Сайдашева в маеиюне 1912 г. в четырех номерах газеты «Баянельхак».

«Бәян әл-хак» газетасының нашире Әхмәтҗан әфәнде бине Яхья Сәйдәшев җәнабләренең үз кулы белән язган тәрҗемәи хәле (автобиографиясе)

Газетабызның бу номерыннан башлап, мәрхүм Әхмәтҗан бабайның тәрҗемәи хәлен дәреҗ итә барачакбыз. Мәрхүм Әхмәтҗан баба иң картларыбыздан булып, милләтебезнең төрле вакытларын күргән һәм шул төрле вакытларда мәйданга чыккан, төрле мәсьәләләргә иштирак иткән зат иде. Бинаән галәйһи, аның тәрҗемәи хәле әфкяре гомумиемез тарихының бер сәхифәсе диерлектер. Вакыйган да бер вакытлар без Русия мөселманнары үзебезгә башка бер хәяте иҗтимагый тәшкил итеп һәм шуның дәирәсенә билгеләнеп ята идек.

Мәгыйшәтебезнең мадди җиһаннарына хисап итмәгәндә, һичбер ноктасында башкаларныкына ошамаган һәм тоташмаган иде.

Хәзерге кеби газеталарыбыз, клубыбыз, спектакльләребез юк, хәтта җәмгыяте хәйрияләребез дә мәйданга чыкмаган, земстволарга һәм шәһәр думаларына сайлауларга әһәмият бирмибез, думага вәкилләр җибәрәсебез дә юк. Бар кеби иҗтимагый эшләребез — мәсҗед салу, мәдрәсә карау, һәм мулла куюдан гына гыйбарәт. Русча, дөнья гамәлләре һәм хатын-кызга язу өйрәнү хәрам дәрәҗәсендә йөртелә диярлек. Халык каршында фәкать мәдрәсәдә укып, голуме диниядән күп мәгълүмат алган кешеләр игътибарда. Фәлән фәләннең шәкерте, ул аның тарафдары. Фәлән фәләннең мөдире эштә, төрле фиркаларга бүленүебез дә шуның белән тәмам буладыр иде.

Менә халкыбыз шундый бер хәлдә вакытта Әхмәтҗан баба Сәйдәшев дөньяга чыга. Авылда заманасының җимеше аның фикерендә шул вакытларда мәйдан тоткан мәсьәләләр ишгаль итәләр. Ләкин вакыт алмашына, әфкяре гомумиебез дә үзгәрә. Берсе артыннан берсе яңа мәсьәләләр мәйданга туа башлыйлар. Ысуле җәдид вә ысуле кадим мәсьәләсе күтәрелә. Русча уку, дөнья гыйлемнәреннән өлеш алу, ана булачак кызларыбызны укыту һәм аларга тәрбия бирүнең лязиме хис ителә башлый. Әхмәтҗан баба бу мәсьәләбезнең барчасын да үткәрә, башлап мөселман балалары өчен русча мәктәпләр дә ачтырып йөри һәм башка мәсьәләләргә дә катыша. Ниһаять, соңгы вакытларыбызга килеп җитәбез, газеталарыбыз мәйданга чыга, съездлар ясыйбыз һәм Думага сайлыйбыз. Әхмәтҗан баба бу мәсьәләләрдән читтә калмый. Шунлыктан мәрхүм Әхмәтҗан бабаның тәрҗемәи хәле бу газетада әйтелгәнчә әфкяре гомумемез тарихының бер сахифәсе диергә ярыйдыр. Файдалана белгән кешеләр аңардан күп гыйбрәт алырлар дип уйлыйбыз.

* * *

«Тәрҗемәи хәл

Йа, мөяссәрел-өмур (башланган эшне башкарып чыгарга язсын иде)!

Әхмәтҗан Сәйдәшев, үземнең тәржемәи хәлемне язарга ният иттем. Вә шуңа бәрабәр тәжрибә мәбна булган бәгъзы тарих һәм кайгымны нәкыль итәчәкмен.

Үзем Казан вилайәте, Лаеш өязе, Кабан каръясендә[1] 1840 елда, 16 июльдә дөньяга килдем.

Газиз әткәм 1810 нчы елда иң әүвәлге мөфти хәзрәтләре хозурында имтихан кылынып, шул ук вакытта җирле мәзкүр Кабан авылына имамлыкка утырган. Минем әткәм Яхья бине Сәйдәш бине Габделвahhаб Тәтеш өязе Яңа Сала дигән авылда дөньяга килмешдер[2]. Бу Габделвahhаб хәзрәт Казанда имамәт кылган Хәммад хәзрәтнең бик якын карендәше булган[3]. Габделвahhабның атасы Катил хәзрәт, аның атасы Дусмөхәммәт мулла, аның атасы Уразбакты, аның атасы Сөбханкол вә аның атасы Болгар шәһәре имамы, имин вә тыныч вакытта Байчура исемле кеше булмышдыр. Әмма бабамызның сәүдәгәрме, гыйлемледәнме, якын беребез мәнсублы адәмле әбәдкә мәгълүм түгелдер. Вә шулай ук шәһре Болгардан Яңа Салага кайсы бабабыз күчкәнлеге дә мәгълүм түгелдер.

Шимди үзебезнең хосусый тәржемәи хәлебезне мәрви итик. Үзем мәзкүр Кабан каръясендә әткәм тәрбиясендә 12 яшемә кадәр гомер иткәннән соңында агаларым ул заман Казан шәһәрендә мөбарәк Мөхәммәткәрим хәзрәт (хәзердә Касыйм хәзрәт мәдрәсәсе) мәдрәсәи мөбәрәкәсендә тәхсиле голүм дә иткән, мине дә әткәм шулар янына Казанга утыртып китерде[4]. Агаларымның хәлфәсе пишкадәм мөхтәрәм Бәһаветдин әфәнде, үзенең шәкертләре күп булганлыктан агалары белән киңәшеп энесе Нуретдин әфәндегә тапшырды. Мин тиз заманда Нуретдин хәлфәнең тырышуы вә тырыштыруы сәясендә гарәп-фарсы китапларыны тәмам итеп, сарыф-нәхү укый башладым. Сарыфтан «Шәрхе Габдулла» вә «Тәркиб» китапларны укыдык. Нуретдин хәлфәбезнең шәкертләре минем белән 17 кеше иде.

Безнең мәдрәсә мәхәлләсендә Исхак бай Апаков дигән бер дәүләтле сәүдәгәр адәм бар иде[5]. Ул бервакыт дамелла Мөхәммәткәрим хәзрәттән «балаларымны укырга бирәсем бар, кайсы хәлфәгә бирим икән, әмма башка балалар укытмыйча минем балаларымны гына укытуны шарт куела» — диеп сораган. Дамелла бераз уйлаганнан соң җавап бирмәкче булып шул көе аерылганнар. Соңрак хәзрәт остабыз Нуретдин әфәндене күреп мәслихәт тарикынча «менә Исхак бай балаларын укырга җибәрмәкче була, сиңа бирсә ничек булыр икән? Һич булмаса фәкыйрлегең сәбәпле бай балалары укыту яхшырак булмас иде микән?» — дигәч хәлфәбез: «мәслихәт күрсәгез, тәкъсир, мин разый» — диеп шатлык белән разый булган.

Шул вакыйгадан соң безнең барчабызны Нуретдин хәлфәдән алып Шиһабетдин хәлфә тәрбиясенә тапшырдылар.

Нуретдин әфәнде шуннан соң фәкать Исхак бай улларына укыта башлады. Шиһабетдин әфәнде соң заман Чар өязе Җанбулат каръясендә имам булып шунда вафат итте (Аллаһ рухына тынычлык бирсә иде, амин). Без бу хәлфәбездән аерылганда, аналарыннан аерылган кош бәпкәләре кабиленнән мәтагъсаф вә ма гыйүс булып калсак та, яңа хәлфәбез Шиһабетдин әфәнденең тырышлыгы сәбәпле үзебезнең ихласан укырга бирелүебез сәясендә ул кадәр үк авыр булмады. Ул заман фәкыйрь шәкертләр арасында Мәкәржә ярминкәсенә аш пешерергә ялланып бару бик гадәттә иде. Мин дә 15 яшемдә вакытта Казанда мех белән сәүдә итүче мәрхүм Габдулла Козловка[6] ялланып ярминкәгә төялгән мех товарлары белән Мәкәржәгә киттем.

Ул заман Канау аръягында (Канавин ягында) һичбер таш бина вә һичбер таш җәйгән мостовойлы урам юк иде, вә шул сәбәбтән, яңгыр яуган саен һәр вакытта тездән былчырак була торган иде.

Шул хезмәттә 20 нче июльдән сентябрь башына кадәр давам иттем. Хуҗам миннән бик разый булып, кайткан вакытта 10 сум акча һәм шактый һәдияләр бирде. Кайтканда азрак пароходлар була башлаган иде, «Сильвестр» исемле пароход белән кайттык.

Хуҗам Габделвәли бай Козловка кайтканда Габделмәннан бай Мөстәкыймов җәнапләре белән бергә кайтырга туры килде[7]. Казанга кайтканда хуҗам Вәли бай минем вә минем хезмәтемнең бик яхшылыгына вә атамның бер фәкыйрь мулла идекенә сөйләп мактаган вә Габделмәннан байга мине хезмәткә алуны тәкъдим иткән. Габделмәннан бай бу эшкә разый булып «яхшы, кайткач алырмын, әткәсенә әйт, минем янына бер килеп китсен» — дигән. Соңрак Вәли бай миңа бу хәбәрне сөйләде. Авылыбыз Казаннан 35 чакрым гына булганлыктан, әткәм мәрхүм икенче көнне үк килеп җитте. Бу эшләр 1856 нчы елның сентябрендә булды. Әткәм ул вакытта 73 нче яшендәге бер карт иде. Әткәмне оста-

зым Мөхәммәдкәрим дамелла хәзрәт белән дә күрештердем. Мәкәрҗәдән дамеллага дип бер пар пычак белән ярым кадак яшел чәй алып кайткан идем, кертеп биргәч бик хәер-дога вә шөкерана кылды.

Иртәгәсен чәй эчкәч әткәм, Мәннан байга барамын диеп чыгып китте. Әмма урамда барган вакытта, өеннән чыгып барышлый Гали шәкерт Госманов[8] очрап, атайны туктатып, әткәй белән күрешкән. Вә хәл-әхвәл бәгъдендә кайчан килгәнлекне вә хәзер кайда барырга җыенганлыкны сорашкан. Әткәй мәрхүм керсез күңелле, простой бер кеше булганлыктан, хәл-әхвәлне сөйләп биргән. Гали бай: «хәзрәт, син Мәннан байга барма, менә сәгать икедә миңа кил, улыңны үзем алырмын» — дигән. Шуннан әткәм мәдрәсәгә кайтып, миңа барчасын сөйләп бирде. Без «әле бер кемгә вәгъдә биргәнебез юк, ярый, Аллаһы боерса, шулай итәрбез» — диеп, Гали бай Госмановка бармакчы булдык. Шуннан соң, өйлә намазыннан соң сәгать ике тирәсендә Гали байның өенә икәүләп киттек. Гали бай безне чәй белән сыйлап хөрмәтләгәч: «хәзрәт, мин синең улыңны алдым, иртәгә Печән базары мәчете астындагы чәй кибетенә эшкә чыксын», — диде. Әмма әткәй: «улымның Яңа Мәкәрҗәдән кайтып килеше, шуңар күрә бер ун көн чамасы авылда торып килергә рөхсәт итегез» — диде. Авылга кайткач, әткәй, моңарчы мулла булганың юк һәм үзең дә сәүдәгә керешәсең килә, диеп күрше авылдагы бер рус алпавыттан мине русча укытуны үтенгән. Әмма башта, үзебезнең остазыбыз Гәбделкәрим хәзрәттән рөхсәт алмыйча, русча укыту яхшы түгел диеп, әткәем хәзрәтләре Казанга барып хәзрәттән шулай-шулай диеп, бик йомшаклык белән генә русча укытырга рөхсәт сораган. Дөрес тә, мәскүр рус алпавыты мәмнүн ният илә разый булган иде, әмма зур ихтилаф чыкты: Мөхәммәдкәрим хәзрәт әткәмнең мәскүр сүзләрен ишеткәч тә гаять ачуланып, гайрәткә килеп: «юк, рөхсәт бирмим, өч улың бар икән, барысы да чыксыннар!» — диеп, миңа русча укырга рөхсәт бирмәгән. Әткәем бик куркып кына: «хәзрәт, тәкъсир мин бары мәслихәт тарикынча гына әйткән идем, ачулана күрмә!» — диеп гафу үтенгән. Шул тарика без, Әхмәтҗан Сәйдәшев, русча уку алмыйча калдык. Гәрчә соңрак кеше таный алмый торган рус язуларыны танырга өйрәнсәк тә, уку-язуның кагыйдәләрен вә сарыф-нәхүне — «грамматиканы» белмәү сәбәпле, яза белми үткәрдем.

Ниһаять, мин мәскүр Печән базары мәчете астындагы Гали бай Госмановның (Гали шәкерт) чәй кибетендә хезмәт итә башладым. Ул вакытта миндәге мәгърифәт, миндәге голум бары яхшы фамилле чәйне такта чәйдән аера алырлык кадәр генә иде. Шулай да Печән базарында ике ай кадәр хезмәт иткәч, хуҗабыз үзенең Гостиныйдагы кибетенә главный приказчик Гали Вәлитов янына хезмәткә менәргә кушты (бу кеше соң заман миңа каената булды)[9]. Бу кеше кул астында ике ел кадәр хезмәт иткәч, ярминкәләргә йөри башладым.

Шул тарика яңадан дүрт ел кадәр хезмәт иткәч, мине хуҗам гостиныйга мөстәкыйль приказчик итеп, аерым кибеткә куйды. Шул кибеттә туктаусыз җиде ел хезмәт иттем. Хезмәтемне вә әхлакымны тәкъдир итеп, хуҗа мине ниһаять үзенең барча сәүдәсенә вә барча малларына камил ышанычлы доверенный вазифасына тәгәен итте. Әлхәмделилләһи, шул көннән хуҗама да, үземә дә, дус-ишкә дә күп файдалар күрсәтеп, халык арасында яхшы гына шөһрәт казана башладым. Шул Гостиныйда торган вакытта, хуҗам Гали абзый Госманов мине үзенең балдызы, Мортаза Зайпин дигән кешенең кызына никахландырды[10]. Бу хатыным үземнең җәмигъ балаларымның анасыдыр.

Шуларның җидесе вафат, сәламәтләре исә, улларым — Мостафа һәм Мөхәммәтҗан, кызларым Хөснижиһан[11] (Исмәгыйль Үтәмешев никахында[12] һәм Бәдержиһан (башта Габделвәли Бакиров[13], аның вафаты соңында Каһарман Уразгилдиев[14] никахында).

Заманда булган мөһим вакыйгалар.

1872 нче елларда Мамадыш өязе Каенсар авылының мулласы, күрше авылының бер таныш керәшен учителенә якшәмбе көн кунакка килгән. Чәй эчеп утырганда сүз ара сүз чыгып, мулла дин мәсьәләләренә керешеп киткән һәм сүз арасында икона хакында тәхкыйранә төрле сүзләр сөйләгән. Соңыннан исә керәшен учителе динебезне мәсхәрә кылды диеп, мулланың өстеннән судка биргән. Бу эш Казанда окружной судта каралачак иде. Мин мулла ягыннан защитник итеп Соколов исемле бик үткен вә оста присяжный поверенный чакырдым. Хезмәт хакы 500 сум түләдек.

Ул заман мәшһүр миссионер Ильминскийның яңа эш күрсәтә башлап, миссионерларның куәтләнгән вакыты иде. Аларның астыртын эш йөртүләре аркасында мулланы Себергә җибәрергә хөкем иттеләр. Әмма шаһитларның бер-берсенә хилаф сөйләүләре сәбәпле, бу эшне Сенатка озаттылар. Без мәскүр присяжный Соколовка дәхи 500 сум биреп, юл расходларын үзебез күтәреп, аны Петербургка җибәрдек. Хөкем тәгаен ителгән көнне Соко-

лов мәхкәмәгә керсә дә, Сенатка пакет килеп төшеп, ул эшне бөтенләй карамыйча, Казан мәхкәмәсе тасдыйк иткән хөкемне тәхкыйк кылганнар.

Казанга кайткач, Соколовны мәхәлли мәгъмүрләр 24 сәгать эчендә Казаннан чыгардылар, мәзкүр мулланы Себергә җибәрделәр.

Шул вакыт Казанда полицмейстр Мослов дигән кеше иде. Ул миңа «Каенсар муллысын Себергә җибәрделәр, Соколовны сөрделәр, инде Әхмәтҗан Сәйдәшевка нәүбәт җитте, аңар мең тәңкә акча түләмәсә, өч-дүрт көннән Себергә китәргә хәзер булып торсын!» — диеп, бер танышым аркылы белдерде. Мин куркуымнан, хәерле каза булсын» — дидем, мең мум бирдем — эш, әлхәмделиллаһи, шулай калды.

1873 нче елларда Казан шәһәр Думасына гласный булып сайландым. Бу елларда мәдрәсәләрдә русский класс ачу хакында яңа низам чыккан иде. Бу көн вакыйгаларының мәйданга тууына сәбәп булды. Мәдрәсәләрегезгә русский класс кертегез дип бик тәклиф итселәр, русский класс булмаган мәдрәсәләрне ябабыз диеп тә кылдылар. Без шул хакта беркадәр уйлаганнан соң мәдрәсәләрдә урын җәһәтеннән бик тыгызлык, шунлыктан русский классларны аерым (русский класс при медресе) ачу мәгъкуль булыр иде, дигән фикерне салырга һәм шул русский классларның расходына шәһәр тарафыннан акча бирдерергә ижтиһад иттеләр.

Ниһаять, шул ук елда, беренче һәм икенче школаны ачтырырга муаффәкъ булдык. Боларның берсенә ислам дине дәресләре укытырга мәшһүр галимебез Сабир хәзрәт Халидине[15] тәгаен иттердек. Мөшаре иләйһи шул школада күп еллар ислам динне тәгълим илә мәшгуль булды. Сабир хәзрәт кеби истикамәтле диянәт сахибе булган бер хәзрәтнең мәзкүр школада ислам дине тәгълим итүе халыкның ул школага кырын карамавына да зур тәэсир итте.

Ул вакытта попечитель Шестаков җәнапләре иде. Бу зат школада мөселманча күбрәк укытыла дип, яңа школалар ачуга каршы төште. Шул сәбәпле, шәһәр Думасында Бишбалтада школа ачу мәсьәләсе каралганда күп читенлекләр күрдек. Шулай ук күп ижтиһадлар сарыф иткәннән соң максатыбызга ирештек, Бишбалтада яңа школа ачылды. Шуның өчен бәгъзе бер артыграк «диянәт» сахибләребез тарафыннан шелтәләр дә ишетелде. Хәлбуки бу көнгәчә школа мөселманнарга (әлхәмделиллаһи шөкер) файдадан башка һичбер нәрсә китергәне юк. Бу ике школага шәһәр Думасы мине попечитель итеп тәгаен кылган иде.

Мин үз тарафымнан косур китермәскә тырышып, егерме еллар шул ләвазымне әда иттем. Ләкин вәжданыма хилаф бер вакыйга заһир булдыкыннан истигъфа итәргә мәҗбүр булдым, миннән соң бу лөзүмгә Хәлил әфәнде Галиев тәгаен иттеләр[16].

1873 нче һәм 1875 нче елларда гласный булганлыгымнан шәһәр Думасында кулымнан килгән кадәр халкыбызга хезмәт итәргә тырыша килдем. Бу вакытларда шәһәрдә безнең мөселман урамнарына таш җәелмәгән иде. Шунлыктан яңгыр вакытларында бик пычрак була иде. Хосусан Большой Мещанский урам яз көннәрендә атка утырып үтә алмаслык бер баткаклык хәленә керә иде. Без исә, күп ижтиһадлар сарыф итеп, шул урамнарга таш җәергә карар иттерергә муаффәкъ булдык, болардан башка да бер ничә мәсьәләләр кузгатырга уйлап тора идек.

Ләкин, Аллаһының казасы, бер бәләгә дучар булу сәбәпле, 1876 нчы елда шәһәр Думасының эшләренә иштирак итәргә туры килмәде. Шул ук сәбәпкә мәбнә алдагы сайлауларга катнаша алмадым.

Бу вакытта мин тыныч кына хуҗамның эшләрен идарә итеп тора идем. Хуҗам бар эшләрен миңа тапшырганлыктан, матди җәһәтемене дә артыгы белән тәэмин иткән иде. Шул сәбәпле, мин яхшы гына байлар шикелле көн кичерә идем. Ләкин, көтелмәгән җирдә бер тәэссефле вакыйганың мәйданга тууы минем бар рәхәтемне җимерде.

Мәзкүр вакыйга ошбуннан гыбарәт. Ул вакытларда Казаныбызда Мортаза исемле бер бай бар иде. Аны халык Кышкар Мортаза дип йөртә иде[17]. Бу кеше үзе бояр табигатьле кеше булсада, дин вә милләт өчен кирәкле урыннарга акча белән ярдәм итә торган иде. Мин мәрхүм Мортаза бай белән югарыда язылган Каенсар мулласы эше артыннан йөргәндә таныштым. Ул шул эшкә акча белән беркадәр ярдәм дә итте.

Мортаза байның бик бай вакыты иде. Имениәләре бик күп булып, тәрәкә вакытында сатып алган кешеләр күп файдалар да иткәләделәр.

Мәсәлән Казанның Әхмәтҗан Үтәмешев[18] дигән бай Кенәр авылы янындагы бер имениясен 40 меңгә (дөрес бәһасе дип әйтә алмыйм, хәтеремнән чыккан) алып, беркадәр юлга салганнан соң 100 меңнән зиядә файда иттеләр. Мортаза байның йорты хәзерге Городской

пассаж урынында иде. Ул үзе шунда тора иде. Печән базарында пахтә сәүдәсе бар иде. 1875 нче елларда пахтәнең бәясе арзанайганлыктан, Мортаза байның сәүдә эшләре чуалып киткән, Мәскәү фирмаларына булган бурычларын вакытында түли алмаган. Шуннан соң аның вексельләре адвокат кулына кергәннәр.

Дуслары, хосусан Муса Уразов[19] дигән кеше, Мортаза байны коткару касды илә кредиторларына ниҗарәдәге малын күрсәтми калдырырга киңәш биргәннәр һәм Казанның могтәбәр кешеләренә бронзовый вексельләр бирергә уйлаганнар. Мондый вексельләр биргән кешеләр: мәрхүм Шиһабетдин әл-Мәрҗани әһлиясе, Мортаза Госманов, Вәли Чукин, Шаһи Зәбиров[20] вә башкалар арысында мин дә бар идем. Мортаза байның дуслары бер байның зур кешесе булганлыктан, мине дә игътибарга алып, 9 мең сумлык вексель бирергә булганнар. Мин яшьлек сәбәпле, ахырын уйламыйча, файдам тапсын дип шундый зур эшкә катышырга җөрьәт иттем һәм Мортаза байның дуслары кушкан адвокатка доверенность бирдем. Бераз вакытлар үткәч, бу дусларга хилаф як адвокатлары Мортаза байны әллә нинди вәгъдәләр биреп, үз якларына авыштырганнар һәм аңардан: «мин фәлән, фәлән кешеләргә акчасыз вексельләр (бронзовый вексельләр) бирдем, минем ниҗарәдә малым бар иде, аны Уразовлар яшерделәр» — дип прокурорга заявление бирдергәннәр. Моннан соң Казан сәүдәгәрләре арасында мисле күрелмәгән бер гауга купты. Вексель алган кешеләрне кайда очратсалар, шунда тәүкыйф итә тордылар. Хуҗам Гали абзый һәм мәрхүм Шиһаб хәзрәт Мәрҗанинең әһлиясен авыру булганлыкларыннан, домашний арест тәхетенә алып, өйләреннән чыкмый торырга ясадылар. Мине полиция мәэмүрләре тотып бишенче частька илтеп яптылар. Бу урында миңа танышларымның булуы беркадәр файда итте. Каенсар мулласының вакыйгасыннан соң танышып калганлыгымнан ул замандагы полиция башлыгы Мослов мине частьтәге гади мәхбүсләр янына яптырмады, приставның кабинетында тотарга кушты. Башта миңа монда яту шактый үк авыр тоелмаса да, бердән гади мәхбүсләр янында булмыйча, пристав кабинетында утырганлыктанмы, икенчедән сакчыларның берничә көннән соң ук яхшы мөгамәлә итә башладыкларыннан, ахырга таба кәеф яхшырды. Шулай итеп мин частьтә өч ай яттым. Әһлиям вә балаларым һәр көн яныма килеп йөриләр иде.

Ул вакытларда Мандельштам дигән минем бер таныш докторым бар иде. Мин шул докторны дәваланырга дип яныма чакырттым һәм шуның аркылы эшнең башында булган следовательгә беркадәр акча биргәннән соң, өч ай тулды дигәндә каенатам Мортаза Зайпин белән Мөхәммәтҗан абзый Галиевка[21] мине порукага алырга рөхсәт иттеләр.

Бу вакыйгаларга катнашлары булган кешеләрдән следователь «вексель акчалымы яки акчасызмы?» — дип бик каты сорагач, акчасыз иде, дип әйтүчеләр булган. Мондый кешеләр бик ансат котылдылар. Әмма мин шулардан хәбәрем булмаганлыктан һәм куркуымнан акчалы дип җавап бирдем. Һәнүз шул сүземне тәкъвия килеп бардым. Бу эш 12-13 елларга тартылды. Суд та берничә мәртәбә бетерелеп, тәкрар кузгатыла торды. Шул сәбәпле мин күп расходландым, 20-30 мең сумга җиттем. Ниһаять, эш соңгы мәртәбә буларак присяжныйларның иштиракы белән Казан окружной судында калды.

Гаеплеләр эскәмиясендә Мортаза бай Госмановны үзен, мине, Чукин Вәлине вә башкаларны һәм Зарастров вә Лавика дигән ике русны утырттылар. (Муса Уразов вафат иткән иде) следователь минем хактагы эшне бетергән булса да, Судебный палата, Сәйдәшевның дуслары күп — котылыр әле, дип мине дә хөкемгә бирергә ясаган. Эш 1888 нче елда 21 нче сентябрьдә карала башлады һәм 5 көн дәвам итте. Ниһаять, Зарастров вә Лавика дигән русларны Себергә хөкем иттеләр, безне коткардылар. Муса Уразов Эстәрлетамакта конкурс члены булып, Мортаза байның чәйләрен сатканда, шул чәйләрне Сәйдәшев алган дип гаепләгәннәр иде. Ул Сәйдәшев мин булмыйча, Муса Уразовның Сәйдәшев дигән приказщигы булып чыкты. Шунлыктан Мортаза байны һәм безне гаепсез таныдылар. Муса Уразов үлгән иде.

Бу урында Мортаза бай хакында берничә сүз әйтеп үтүне лязем табамын. Кышкар Мортаза дип мәшһүр бу зат үзен кибарларча тота торган иде. Голәма һәм кунаклар мәҗлескә җыйналып беттеләр, дип йорт хуҗасы чакырырга җибәрсә, Мортаза бай хәзер генә йокларга ятты, торгач барыр, дип әйтегез, дип җибәрә торган иде. Шулай итеп өйләдән кичкә кадәр көткән мәҗлесләр була торган иде. Мортаза һәм хатыны бик мөсриф кешеләр иде. Бервакыт мәрхүмнең кызы Үлмәсбикә кечкенә вакытта Арсаев Хәйрулла[22] исемле кешенең кызы белән курчак бирешү туе ясап 20 табын кунак һәм галимнәр җыйганнар. Хәтта 30-40 ат придан бирелгән диеп тә сөйлиләр. Бу вакыйга хакында судта сүзләр булды. Мәрхүмнең

кызы Үлмәсбикә Исмәгыйль бай улы Солтанкайда ирдә иде[23]. Солтанкай факыйрьлектә вафат итте. Үлмәсбикә хәзерендә сәламәт булып, гаять мохтаҗлыкта көн кичерәдер. Аның өстенә мескен үзе тагын аяксыз да. Хәлләреннән килгән кешеләр ярдәм итсәләр, бик урынлы булыр.

Минем бу вакыйганы язуымның максаты, яшьлек сәбәпле нинди бәлагә очраганлыгымны укучыларга гыйбрәт итеп күрсәтү һәм кыскача гына булсада, Мортаза байның мәгыйшәтен тасвир кылып, әүвәлләрдә байларыбызның нинди нәрсәләргә әһәмият биргәнлекләрен аңлату иде. Инша Алла, беркадәр муаффәкъ булганыбыздыр, дип уйлыйм».

Бәян әл-хак. – 1912. – 14, 16 май, 8, 27 июнь.

ПРИМЕЧАНИЯ:

1. Ныне д. Татарский Кабан Лаишевского района РТ.
2. Сайдашев Яхья (1783-1876) — уроженец д. Янасалы (ныне Камско-Устьинский район РТ), имам-хатиб мечети д. Татарский Кабан.
3. Халиди Хаммад (1799-1865) — уроженец д. Янасалы, имам-хатиб Четвертой соборной мечети г. Казани, известный проповедник и педагог. Род Халиди связывали родственные отношения с родом Сайдашевых.
4. Мухаметрахимов Мухаметкарим (1805-1865) — имам-хатиб Апанаевской мечети, мударрис «Приозерного» (Апанаевского) медресе.
5. Апаков Исхак Муртазович — торговец мануфактурой, казанский купец 1-й гильдии, потомственный почетный гражданин.
6. Козлов Габдельвали — казанский торговец мехами.
7. Мустакимов Габдельманнан Биккенеевич (1808-1869) — уроженец д. Б. Берези (ныне Атнинский район РТ), торговец хлебо-бакалейными и мануфактурными товарами, казанский купец 1-й гильдии, попечитель Четвертой соборной мечети г. Казани.
8. Усманов Мухаметгали Габсалямович (1801-1878) — уроженец д. Карелино (ныне Балтасинский район РТ), торговец хлебо-бакалейными и мануфактурными товарами, казанский купец 1-й гильдии, потомственный почетный гражданин.
9. Валидов Мухамедгали (1827-?) — приказчик М-Г. Г. Усманова, позднее казанский купец 2-й гильдии.
10. Зайпин Муртаза Мухаметович (1806-1878) — казанский купец.
11. Сайдашев Мустафа Ахметзянович (1863-?), Сайдашев Мухаметзян Ахметзянович (1865-1914), Сайдашева Хусниждиган Ахметзяновна (1869-?), Сайдашева Бадриджиган Ахметзяновна (1879-1913) — дети А. Я. Сайдашева.
12. Утямышев Исмагил Мухаметгарифович (1863-?) — промышленник, общественный деятель, казанский купец 1-й гильдии, потомственный почетный гражданин.
13. Бакиров Габдельвали — казанский предприниматель.
14. Уразгильдеев Кахарман Ибрагимович (1872-?) — казанский купец 2-й гильдии.
15. Речь идет, скорее всего, о Халидове Мухамедсабире Хаммадовиче (1836-1911), имам-хатибе Четвертой соборной мечети г. Казани.
16. Галеев Халиулла Хабибуллович (1839-1909) — уроженец д. Большие Кибяккози (ныне Тюлячинский район РТ), торговец мануфактурой, казанский купец 2-й гильдии, общественный деятель.
17. Усманов Муртаза Мустафич (1823-?) — уроженец д. Кшкар (ныне Арский район РТ), казанский купец 1-й гильдии, потомственный почетный гражданин, промышленник, попечитель Кшкарского медресе.
18. Утямышев Ахметзян Мусич — уроженец д. Маскары Малмыжского уезда Вятской губернии (ныне Кукморский район РТ).
19. Уразов Муса Исхакович (1842-?) — казанский купец 2-й гильдии.
20. Марджани Шигабутдин (1818-1889) — имам-хатиб Первой соборной мечети Казани, богослов, ученый, педагог; Чукин Абдулвали Юсупович (1824-1895) — казанский купец 2-й гильдии, благотворитель; Забиров Шагиахмед Фахрутдинович (1835-?) — казанский купец 2-й гильдии.
21. Галеев Мухаметзян Ибнаминович (1832-1908) — казанский купец 1-й гильдии, производитель и торговец азиатской обуви, общественный деятель, отец Г. Баруди.
22. Арсаев Хайрулла Курбангалеевич (1838-?) — казанский купец 2-й гильдии, потомственный почетный гражданин.
23. Апаков Мухаметсултан Исмагилович — сын казанского купца 1-й гильдии Исмагила Исхаковича Апакова, потомственный почетный гражданин. Был женат на дочери М. М. Усманова Улмяскамале (по А. Я. Сайдашеву — Ульмясбике).

Радик Салихов,
кандидат исторических наук
Лилия Мухамадеева,
соискатель Института истории им. Ш. Марджани АН РТ